**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ НИЖНЕКАМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
423114, СЕЛО НИЖНЯЯ КАМЕНКА, УЛ.ЦЕНТРАЛЬНАЯ, Д. 51

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КӘМИНКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423114 ТҮБӘН КӘМИНКӘ АВЫЛЫҮЗӘК УРАМЫ, 51 ЙОРТ

Тел.: (84396)2-35-21
Email: NkamCmn2@tatar.ru

№ 40 23сентябрь 2021

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 8 августындагы 63 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кәминкә авыл җирлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 августындагы 63 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына (2017 елның 12 октябрендәге 70 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «территорияне төзекләндерү - авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру, гражданнарның яшәү шартларын яхшырту, авыл җирлеге территориясенең санитар һәм эстетик

торышын яхшырту, торак пунктларның һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларның, шул исәптән гомуми кулланылыштагы территорияләр, җир участоклары, биналар, төзелешләр, корылмалар территорияләрен карап тоту буенча эшчәнлек».;

1.2. 6 пунктның 44 абзацын бәян итәргә «территорияне төзекләндерү - территорияне карап тоту, шулай ук территорияләрне төзекләндерү элементларын проектлау һәм урнаштыру буенча, гражданнарның яшәү шартларын тәэмин итүгә һәм комфортлы итүгә, территориянең санитар һәм эстетик торышын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар комплексы;

1.3. 6 пунктның 30 абзацын бәян итәргә: «стационар булмаган сәүдә объекты - вакытлыча корылмадан яисә вакытлыча конструкциядән торган, инженерлык-техник тәэминаты челтәрләренә тоташтырылу (технологик тоташтырылу) булу яки булмауга бәйсез рәвештә җир участогы белән тыгыз бәйләнештә булмаган сәүдә объекты, шул исәптән күчмә корылма»;

1.4. 6 пунктның 64 абзацын бәян итәргә: «төзекләндерү элементлары - декоратив, техник, планировка, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, төрле җиһазлар һәм бизәлеш элементлары, шул исәптән биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның фасадларының, кече архитектура формаларының, капиталь булмаган стационар булмаган төзелешләр һәм корылмаларның, территорияне төзекләндерүнең состав өлешләре буларак кулланыла торган мәгълүмат щитлары һәм күрсәткечләренең»;

1.5. 10 пунктны бәян итәргә: «10. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм җыештыру «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2021 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне башкару буенча конкурста җиңгән махсус оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла»;

1.6. 35 пунктны бәян итәргә «35.Юлларны карап тоту «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2021 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне башкару буенча конкурста җиңгән махсус оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла»;

1.7. 73 пунктны бәян итәргә «73. Кече архитектура формаларын карап тоту, бирелгән җир кишәрлекләре чикләрендә җир кишәрлекләре хуҗалары тарафыннан гамәлгә ашырыла, гомуми файдаланудагы территорияләрдә - вәкаләтле орган тарафыннан «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2021 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне башкару буенча конкурста җиңгән оешма белән шартнамә нигезендә вәкаләтле орган белән тәэмин ителә;

1.8. 85 пунктны бәян итәргә «85.Җирләү урыннарын санитар тәртиптә тотуны «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2021 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне башкару буенча конкурста җиңгән махсуслаштырылган оешма гамәлгә ашыра;

1.9. 12 пунктның 2 пунктчасын бәян итәргә: «2) гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр чикләрендә – вәкаләтле орган яки «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2021 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне башкару буенча конкурста җиңгән махсуслаштырылган оешма;

1.10. 64 пунктның 1 абзацын бәян итәргә «64.Тышкы яктыртуның бердәм системасына тоташтырылган урам һәм йорт яны утларын карап тоту һәм ремонтлау эшләрен вәкаләтле орган яки «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2021 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне башкару буенча конкурста җиңгән махсуслаштырылган оешма башкара.

1.11. 125 пунктның 14 абзацын бәян итәргә: «-сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләрен, шул исәптән палаткалар, киосклар, лареклар, мини-базарлар, павильоннар, җәйге кафелар, җитештерү объектларын, автомобильләрне, көнкүреш техникасын, аяк киемен вак-төяк ремонтлау предприятиеләрен, шулай ук кунаклардан кала автостоянкаларны урнаштыру. Тиешле тәртиптә төзелгән

һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләренең милекчеләре өчен аларга стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында карар кабул итеөә, әгәр дә бу Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Түбән Кәминкә авыл җирлеге
башлыгы, Советы рәисе